КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 февраль г.Казань № 141

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче; 2016 ел, 9 август, 547 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 39 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 206 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 874 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1099 нчы; 2019 ел, 9 сентябрь, 805 нче; 2020 ел, 3 декабрь, 1091 нче; 2021 ел, 19 июль, 593 нче; 2022 ел, 3 июнь, 519 нчы; 2022 ел, 3 октябрь, 59 нчы, 2022 ел, 15 ноябрь, 1217 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында 14 нче таблицага карата «СП 118.13330.2012 «Иҗтимагый биналар һәм корылмалар. СНиП 31-06-2009 актуаль редакциясе» сүзләрен «СП 118.13330.2022 «Иҗтимагый биналар һәм корылмалар. СНиП 31-06-2009» сүзләренә алмаштырырга;

35 нче таблицаның 9.3 пунктындагы 4 нче графасының беренче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле)

һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин